**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының**
**Каенсар авыл җирлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**11 ноябрь, 2024 ел** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлеге Каенсар авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 29 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегенең Каенсар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә. Гражданнар җыенын Каенсар авылы, Һ.Такташ ур., 23 адресындагы авыл клубы бинасында уздырырга.

2. 2024 елның 29 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегенең Каенсар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә. Гражданнар җыенын Каенсар авылы, Һ.Такташ ур., 23 адресындагы авыл клубы бинасында уздырырга.

3. 2024 елның 30 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегенең Каенсар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә. Гражданнар җыенын Каенсар авылы, Һ.Такташ ур., 23 адресындагы авыл клубы бинасында уздырырга.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Каенсар авыл җирлеге Каенсар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 яки аннан да күбрәк бала тәрбияләүче күп балалы гаиләләрдән; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Каенсар авылының Яшьләр урамында су белән тәэмин итү челтәрләрен, су суырту манараларын һәм су саклау зоналарын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, шул исәптән, су суырту манаралары өчен идарә итү станциясе, автоматика, насослар сатып алу һәм урнаштыру, суга скважина бораулау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;)

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Каенсар авылында юлларны карап тоту, шул исәптән Каенсар авылы юлларын кардан чистарту, трактор тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр, комплектлау материаллары сатып алу, тракторчы хезмәтләре, трактор өчен тагылма җиһазлар сатып алу, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; Мәктәп, Г. Тукай урамнарына, вак таш салып, юллар төзү һәм чокырларны ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;)

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Каенсар авылында ял итү зонасын, спорт һәм балалар уен мәйданчыгын һәм аның тирәсендәге территорияне төзү, төзекләндерү һәм ремонтлау, шул исәптән, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; массакүләм ял итү урыннарын, мәдәни чаралар уздыру урыннары һәм башка массакүләм ял итү урыннарын һәм янәшәдәге территорияләрне төзү, тоту, төзекләндерү, җиһазландыру һәм ремонтлау, массакүләм ял итү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре, шул исәптән, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.)

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар тоту, төзекләндерү, (Каенсар авылындагы зиратны төзекләндерү һәм карап тоту, агачларны кисү,гербицидлар, зират өчен җиһазлар һәм инвентарь сатып алу, шул исәптән, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;)

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүлү.

6. Каенсар авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Каенсар авыл җирлеге башлыгы И.Х. Исхаков